СОВЕТ БУРНАҚСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БОРНАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
29.11.2024

КАРАР
№ 115

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» гы 27.03.2024 № 101 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»гы 27.03.2024 № 101 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның «б» пунктчасында «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 пунктның «в» пунктчасына «, әлеге пунктчада күрсәтелгән, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга,шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Борнак авыл җирлеге башлыгы Ш.М.Хабибуллин